| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| С О В Е Т<br>Нижнекамского муниципального района | Түбән Кама муниципаль районы<br>С О В Е Т Ы |
| 423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12<br>факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12<br>факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41 |


Р Е Ш Е Н И Е    К А Р А Р

№ 28    2021 елның 23 апреле

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2018 елның 29 июнендә кабул ителгән «Хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау турында» 50 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» федераль законнар, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2018 елның 29 июнендә кабул ителгән «Хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау турында» 50 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.3 пунктның б пунктчасында «мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу таләпләре» сүзләреннән соң «, шулай ук алар тарафыннан 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итү турында» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләренә карата вазыйфа тәртибенә һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында»;

1.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«муниципаль хезмәт ваыйфасын биләүче затның коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә хәбәр итү буенча»;

5 бүлекнең атамасында «комиссия тарафыннан карау тәртибе» сүзләрен «Вазыйфа тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә кагылышлы мәсьәләләрне» сүзләреннән соң өстәргә;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1 комиссия утырышын уздыру өчен нигез булып тора:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелгән оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан тапшырыла торган

белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын һәм оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи тәртибенә карата таләпләрне үтәүне, оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләрне тапшыру турында муниципаль норматив хокукый актларда каралган дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләрнең оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан тапшырылуын таныклаучы тикшерү материалларын тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан тапшыру;

б) муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә оешма (учреждение) җитәкчесенең объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

в) комиссиягә кергән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәре (алга таба - хәбәрнамә)»;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне яки гаризаны алдан карый һәм аны карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.»;

5.3 пунктның беренче абзацында «хәбәрнамә» сүзен «хәбәрнамә яки гариза» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында «Хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә;

5.3 пунктның өченче абзацында «хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә;

5.4 пунктта «күрсәтелгән мәсьәлә» сүзләрен «күрсәтелгән мәсьәләләр» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктның беренче җөмләсендә «тапшырган затның» сүзләрен «тапшырган затларның» сүзләренә алмаштырырга, «хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктның икенче җөмләсендә «хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә, «хәбәрнамәдә» сүзләреннән соң «яисә гаризада» сүзләрен өстәргә;

5.6.1 пунктында «тапшырган затның» сүзләрен «тапшырган затларның» сүзләренә алмаштырырга, «хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә;

«а» пунктчасында «хәбәрнамәдә» сүзләреннән соң «яисә гаризада» сүзләрен өстәргә, «хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасында «хәбәрнамә» сүзеннән соң «яисә гариза» сүзләрен өстәргә;

пункт 5.9 изложить в следующей редакции:

5.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Комиссиянең әлеге бүлекнең 5.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне яки гаризаны карау буенча эш нәтиҗәләре.

5.9.1. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;

б) оешма (учреждениеләр) җитәкчесе тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөрес түгеллеген һәм (яки) тулы булмаганлыгын билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә оешма (учреждение) җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

5.9.2. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән гаризаны карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәүнең сәбәбе объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәүнең сәбәбе нигезле түгел дип танырга. Бу очракта комиссия оешма (учреждение) җитәкчесенә әлеге мәгълүматларны бирү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәүнең сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырудан читләшү ысулы булуын танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә оешма (учреждение) җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

5.9.3. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны башкарганда, мәнфәгатьләр каршылыгы булмавын танырга;

б) оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны башкарганда, шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия оешма (учреждение) җитәкчесенә, һәм (яки) җирле үзидарә органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яки аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәвен танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә оешма (учреждение) җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә».

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның, яллаучы вәкиленең коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәне комиссия тарафыннан карау тәртибе

6.1. Муниципаль хезмәткәргә карата комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып тора:

а) яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хезмәткәрдән кергән коррупциячел хокук бозу кылуга тарту турындагы хәбәрнамәсе белән комиссиягә мөрәҗәгать итүе;

б) яллаучы (эш бирүче) вәкиленең гражданнардан, юридик затлардан, муниципаль хезмәткәрләрдән һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлардан коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында, аларның вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле нинди дә булса затларның муниципаль хезмәткәрләргә мөрәҗәгате фактлары турында кергән мәгълүмат белән Комиссиягә мөрәҗәгать итүе.

6.2. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый.

6.3. Комиссия рәисе аңа норматив хокукый акт белән каралган тәртиптә, Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алган мәгълүмат кергәндә:

а) хәбәрнамәдә булган мәгълүматларны тикшерүне оештыра;

б) аңа карата мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрдән язма аңлатмалар сорый, хезмәткәрне коррупциячел гамәлләр кылуга этәргән шартларны билгели, компетенция кысаларында муниципаль хезмәткәр тапшырган мәгълүматны һәрьяклап карау өчен кирәкле башка чараларны гамәлгә ашыра.

Хәбәрнамәдә булган мәгълүматларны тикшерү эш бирүче вәкиле тарафыннан аны үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә үткәрелә;

в) Комиссия утырышы датасын 10 көн эчендә билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калып билгеләнә алмый;

г) аңа карата мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең яисә карала торган мәсьәләгә катнашы булган комиссия әгъзасының үтенечнамәләрен карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында карала торган мәсьәләгә карата булган өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

6.4. Комиссия утырышы аңа карата мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр катнашында уздырыла, әгәр дә муниципаль хезмәткәр яисә граждан үзе катнашырга ниятләве турында Комиссия утырышында белдерсә.

6.5. Комиссия утырышлары муниципаль хезмәткәрсез түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр хәбәрнамәдә муниципаль хезмәткәр яисә гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтмәләр юк икән;

б) комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнгән һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән муниципаль хезмәткәр Комиссия утырышына килмәсә.

6.6. Комиссия утырышында муниципаль хезмәткәрнең һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук карала торган мәсьәләгә караган өстәмә материаллар карала.

6.7. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында үзләренә билгеле булган мәгълүматларны игълан итәргә хокуклы түгел.

6.8. Әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлеше таләбен үтәде һәм аны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту очрагы турында яллаучы вәкиленә хәбәр итте дип билгеләргә;

б) муниципаль хезмәткәр «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлеше таләбен үтәмәде һәм аны коррупцион хокук бозу кылуга тарту очрагы турында яллаучы вәкиленә хәбәр итмәде дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия эш бирүчегә гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

6.9. Комиссия карарларын үтәү өчен җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары, билгеләнгән тәртиптә эшкә алучы вәкиленә карап тикшерүгә тапшырыла торган яллаучы вәкиленең карарлары яки күрсәтмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин.

6.10. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән коллегиаль рәвештә кабул ителә.

6.11. Комиссия карары комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

6.12. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре;

б) Комиссия утырышында карала торган мәсьәләнең, аңа карата мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтеп, формулировкасы;

в) коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аларның вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле нинди дә булса затларның муниципаль хезмәткәргә мөрәҗәгать итү очраклары турында билгеле булган хәлләрне тасвирлау (датасы, урыны, вакыты, башка шартлар);

г) мөрәҗәгать иткән затлар үтенече буенча муниципаль хезмәткәр башкарырга тиеш булган коррупцион хокук бозулар турында тулырак белешмәләр;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, әтисенең исеме һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителеше;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләр булган мәгълүмат чыганагы, җирле үзидарә органнарына мәгълүмат керү датасы;

ж) карала торган мәсьәләгә караган башка мәгълүматлар;

з) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

6.13. Аның карары белән килешмәгән Комиссия әгъзасы Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри кушылырга тиешле һәм муниципаль хезмәткәр аның белән танышырга тиеш булган үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

6.14. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш уздырылган көннән 7 көн эчендә яллаучы вәкиленә, тулысынча яки аннан күчермәләр рәвешендә - муниципаль хезмәткәргә, шулай ук Комиссия карары буенча карала торган мәсьәләгә катнашы булган башка кызыксынган затларга җибәрелә.

6.15. Эш бирүче вәкиле комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм үз компетенциясе кысаларында муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул иткәндә, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча булган тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында яллаучы вәкиле комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән бер ай эчендә Комиссиягә язма рәвештә хәбәр итә. Яллаучы вәкиленең карары комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча гына игътибарга алына.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин